

## Январь аенда кояш чыгу, кояш бату һәм намаз уку вакытлары

| Көннәр | Иртәнге намаз | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Кояш бата Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 7.23 | 8.53 | 13.05 | 14.45 | 16.35 | 18.05 |
| 2 | 7.23 | 8.53 | 13.05 | 14.46 | 16.36 | 18.06 |
| 3 | 7.23 | 8.53 | 13.05 | 14.47 | 16.37 | 18.07 |
| 4 | 7.23 | 8.53 | 13.05 | 14.47 | 16.37 | 18.07 |
| 5 | 7.23 | 8.53 | 13.05 | 14.48 | 16.38 | 18.08 |
| 6 | 7.22 | 8.52 | 13.05 | 14.51 | 16.41 | 18.11 |
| 7 | 7.22 | 8.52 | 13.05 | 14.52 | 16.42 | 18.12 |
| 8 | 7.21 | 8.51 | 13.05 | 14.53 | 16.44 | 18.14 |
| 9 | 7.21 | 8.51 | 13.05 | 14.55 | 16.45 | 18.15 |
| 10 | 7.20 | 8.50 | 13.05 | 14.56 | 16.47 | 18.17 |
| 11 | 7.19 | 8.49 | 13.05 | 14.57 | 16.48 | 18.18 |
| 12 | 7.19 | 8.49 | 13.05 | 14.57 | 16.48 | 18.18 |
| 13 | 7.18 | 8.48 | 13.05 | 15.00 | 16.51 | 18.21 |
| 14 | 7.17 | 8.47 | 13.05 | 15.02 | 16.53 | 18.23 |
| 15 | 7.16 | 8.46 | 13.05 | 15.03 | 16.54 | 18.24 |
| 16 | 7.15 | 8.45 | 13.05 | 15.05 | 16.56 | 18.26 |
| 17 | 7.14 | 8.44 | 13.05 | 15.07 | 16.58 | 18.28 |
| 18 | 7.13 | 8.43 | 13.05 | 15.08 | 16.59 | 18.29 |
| 19 | 7.13 | 8.43 | 13.05 | 15.08 | 16.59 | 18.29 |
| 20 | 7.11 | 8.41 | 13.05 | 15.12 | 17.03 | 18.33 |
| 21 | 7.10 | 8.40 | 13.05 | 15.13 | 17.05 | 18.35 |
| 22 | 7.08 | 8.38 | 13.05 | 15.15 | 17.06 | 18.36 |
| 23 | 7.07 | 8.37 | 13.05 | 15.17 | 17.08 | 18.38 |
| 24 | 7.06 | 8.36 | 13.05 | 15.18 | 17.10 | 18.40 |
| 25 | 7.04 | 8.34 | 13.05 | 15.20 | 17.12 | 18.42 |
| 26 | 7.04 | 8.34 | 13.05 | 15.20 | 17.12 | 18.42 |
| 27 | 7.03 | 8.33 | 13.05 | 15.22 | 17.14 | 18.44 |
| 28 | 7.00 | 8.30 | 13.05 | 15.26 | 17.18 | 18.48 |
| 29 | 6.59 | 8.29 | 13.05 | 15.27 | 17.20 | 18.50 |
| 30 | 6.57 | 8.27 | 13.05 | 15.29 | 17.21 | 18.51 |
| 31 | 6.55 | 8.25 | 13.05 | 15.31 | 17.23 | 18.53 |

*Намаз вакытлары турында мәгълүматларны Самара өлкәсе мөселманнарының Региональ Диния нәзарәте хезмәткәрләре әзерләде, мөфти Талип хәзрәт ЯРУЛЛИН раслады. Җомга көннәре аерып күрсәтелгән.*


**Учредители: трудовой коллектив редакции газеты «Бердэмлек» и Региональное Духовное управление мусульман Самарской области.**

**Оештыручылар: «Бердәмлек» газетасы редакциясенең хезмәт коллективы һәм Самара өлкәсе мөселманнарының Региональ Диния нәзарәте.**



بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

# Кыйбла

„БЕРДӘМЛЕК" ГАЗЕТАСЫНЫҢ АЙЛЫК ДИНИ КУШЫМТАСЫ

№ 12
2012 ел
декабрь




*ВӘГАЗЬ*

# Фотога төшү һәм өйдә фоторәсем тоту турында

Пәйгамбәребезнең сурәтләр булган өйгә фәрештәләр кермәве һәм аларны барлыкка китергән кешенең Кыямәт көнендә иң авыр газаплар кичерәчәге хакында әйтелгән хәдисләре мәгълүм. Аларны монда китереп торырга кирәкми, чөнки аларны кире кагучы кеше юк. Бу хәдисләргә аңлатма бирүчеләр турында сөйләп китү яхшырак булыр.

Имам ән-Нәвави сыннарны барлыкка китерүчеләрнең Кыямәт көнендә авыр газапларга дучар ителәчәге турында сүз барган хәдисләрдә потларны, аларга табыну өчен яки үзләрен Барлыкка Китерүчегә тиңләштерү максаты белән барлыкка китерүчеләр күз алдында тотылуын әйтә. Әгәр әйтелгән максатларның берсе дә күз алдында тотылмаса, ул чакта әлеге кеше кәферлеккә төшкән кеше булмый - ул зур гөнаһ кыла. Аңа карата «иң авыр газапларга дучар ителә» дигән гыйбарәне куркыту төсмерендәге сүзләргә кертү яхшырак. Аларның мәгънәсе якынча түбәндәгедән гыйбарәт: мәсәлән, эти-әниләр үзләренең балаларына тыңлаулы булырга, шелтә белдерерлек һәм начар эшләр эшләмәскә кушалар, шулай булмаганда аларга коточкыч юллар белән җәза бирәчәкләрен әйтәләр. Әмма куркытып, алар чынлыкта аларга карата нинди дә булса куркыныч эшләячәкләрме соң? Барлыкка китерүчеләргә үзләренең сыннарына җан кертергә боеруны, эти-әниләр балаларының көченнән килмәгәнлеген алдан ук белсәләр дә, аларга нәрсәдер эшләргә рөхсәт иткәнгә якын куркыту кебек кенә кабул итәргә кирәк.

Сөләйман пәйгамбәр заманында аңа кадәр яшәгән пәйгамбәрләрнең таштан, бакырдан һәм агачтан ясалган сыннары гыйбадәтханә эченә куела торган булган. Бу сыннар кешеләр аларга карап, шул пәйгамбәрләр турында искә алсыннар һәм аларда Аллаһы Тәгаләгә әлеге пәйгамбәрләр хезмәт иткән кебек хезмәт итү теләге уянсын өчен һәм шулай ук нинди дә булса яхшы кешенең үлеменнән соң аның кабере өстендә гыйбадәтханә торгызып, сурәтләр урнаштырсыннар өчен куелганнар. Бүгенге көндә без потлар (сыннар) дип атаган нәрсәләр ул вакытта тыелган булмаган, чөнки ул чакта кешеләрнең ниятләре дә саф булган. Аннан соң кешеләрнең ниятләре үзгәреп, алар төрле барлыкка китерелгән потларга табына башлагач, сыннар тыелган. Ә хәзер уйланыгыз!

Әмма без әле генә алып барган сөйләшүдә фотоаппарат ярдәмендә ясалган фотографияләр күз алдында тотылмавына игътибар итегез. Сүз сыннар – һәйкәлләр, скульптуралар турында бара, ә төшерелгән фоторәсемнәрнең моңа бернинди катнашы да юк.

Мәккәгә ислам килгәнче Кәгъбә потлар белән тулган булган. Һәр ыругның үз потиләһе булган. Безнең Пәйгамбәребез мәккәле-кораешлыларны Бераллалыкка чакыра, өнди башлагач, алар ни рәвешле бер Аллаһы бөтен кешелек өчен дә җитәрлек булуын аңламыйча, аңа каршы күтәрелгәннәр. Бу хәдисләрне аңлатучы имамнар аларны потларны гәүдәле итеп һәм Аллаһыга табынган кебек аларга табыну өчен барлыкка китерүчеләргә кертәләр. Әйдәгез әлеге имамнарның юлын дәвам итүче хәзерге дин белгечләренең ни әйтүен карап китик.

Югарыда китерелгәннәрдән кәгазьдәге сурәтләрнең, шул исәптән фотографияләрнең дә, тыелган булмавы һәм китерелгән хәдисләрдә потлар - гәүдә формасына ия булган сыннар гына күз алдында тотылуы ачык аңлашыла. Дүрт дини-хокукый мәктәпнең (мәзһәб) галимнәре мондый уртак фикергә килгәннәр: җаны булмаган әйберләрне, мәсәлән, кояш, ай, агачлар, өй, мәчет һәм башканы сурәтләргә ярый. Шулай ук дин белгечләре түбәндәге өч шарт булганда җанлы әйберләрне, мәсәлән, кешене һәм хайваннарны ясау рөхсәт ителми дигән фикергә килгәннәр:

- әгәр ул гәүдә формасына ия яки нәрсәдән дә булса ясалган икән. Әгәр инде ул тукымага яисә кәгазьгә ясалган булса, бу рөхсәт ителә;
- әгәр сын тулы, бөтен килеш булса. Әгәр дә ул кешенең яки хайванның яшәве мөмкин булмаслык итеп, мәсәлән, кешенең